

# Алабуга Марина Цветаеваны искә алды






**1941 елның 31 августында Чулман буендагы Алабуга шәһәрендә бөек ватандашыбыз, XX гасырның иң зур рус шагыйрьләреннән берсе булып танылган Марина Ивановна Цветаева чарасызлыктан үз-үзенә кул сала.**

**Тагын 61 елдан соң, 2002 елның 29-31 августында, Алабугада Марина Цветаеваны искә алу көннәре булып узды.**

29 августта, аның истәлегенә багышлап, "Хисләр хакыйкате шагыйре" ("Поэт предельной правды чувства") дигән халыкара фәнни-гамәли конференция оештырылды. Анда Япониядән, Италиядән һәм Россиянең төрле почмакларыннан (Мәскәү, Казан, Хабаровск, Ижевск һәм башка шәһәрләреннән) килгән иллеләп каләм әһеле катнашты. Чыгышларда төп игътибар шагыйрәнең катлаулы язмышына һәм күпкырлы иҗатына бирелде.



Марина Цветаеваның шигырьләре шулай ук итальян һәм япон телләрендә дә яңгырады.

Шигъри сүз остасының соңгы көннәре турындагы "Исход" дигән документаль фильм конференциядә катнашучыларның күңелендә онытылмас эз калдырды.

Делегатлар һәм кунаклар, Цветаева эзләре буйлап, Чистай шәһәренә дә бардылар, Покров чиркәвендә шагыйрә истәлегенә багышланган гыйбадәттә катнаштылар, мәрхүмә каберенә чәчәкләр салдылар.

31 августта - шагыйрәнең фаҗигале үлеме көнендә - Алабуга шәһәрендә Марина Цветаевага Россиядә беренче һәйкәл ачу тантанасы булды. Аның авторлары - Мәскәү скульпторлары Александр Головачев һәм Владимир Демченко. Шушы тантанада Мәскәүдән шагыйрә сеңлесенең оныгы Ольга Трукачева да катнашты. Сәламләү сүзләре белән республикабызның вице-премьеры Зилә Вәлиева, Мәскәү язучысы Лидия Либединская, Алабуга шәһәренең хакимият башлыгы Илшат Гафуров, Цветаева иҗаты белгече, шагыйрә турындагы китаплар авторы Лев Мнухин һәм башкалар чыгыш ясады.

Беренче халыкара Цветаева укулары Чулман буендагы шәһәр белән генә чикләнеп калмыйча, ә бөтен республика, хәтта бөтен илебез күләмендә истәлекле вакыйгага әверелде.

**Рафаэль МОСТАФИН.**

Рәсемнәрдә: М. Цветаева каберенә чәчәкләр салу; шагыйрәгә һәйкәл ачу тантанасында язучы Лидия Либединская чыгыш ясый.



**25 августта Казанда, 1 Май мәйданындагы Муса Җәлил һәйкәле янында каһарман-шагыйрь һәм аның көрәштәшләре истәлегенә багышланган традицион митинг булып узды.** Бу җыен - Плетцензее төрмәсендә җәзалап үтерелгән кыю герой-антифашистларны искә алу мәрасиме иде. Митингта ТР Президент Аппараты җитәкчесе Экзам Гобәйдуллин, ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Роберт Миңнуллин, мәдәният министры Илдус Тарханов, язучылар, артистлар, шагыйрьнең туганнары һәм якыннары, шулай ук күпсанлы шигырь сөючеләр катнашты.

Митингтан соң әлеге искә алу чарасы М. Җәлилнең фронтка киткәнче яшәгән фатирында, хәзерге музей-йортында дәвам итте. Анда "Мусада кунакта" дигән күргәзмә ачылды. Күргәзмәдә каһарман-шагыйрьнең Мостафа авылындагы туган йорты күренешләре чагылдырылган иде.

**ТР Милли музеенда III Бөтендөнья татар конгрессына багышланган "Татарстан символлары" дигән күргәзмә булып узды. Ул республикабызда революциядән соңгы елларда һәм XX гасырның 90 нчы елларында дәүләтчелекнең торгызылуы темасына багышланды.**

Күргәзмәгә милли азатлык хәрәкәте җитәкчеләренең төрле фоторәсемнәре, документлары, шәхси әйберләре, Татарстан Республикасы гербы проекты куелды. Татарстанның бүгенге символларына, дәүләт символикасы төшерелгән төрле сувенирларга, басма продукцияләргә аерым урын бирелде.

**ТР Рәссамнар берлегенең күргәзмә залында яшь рәссам-абстракционист Рамин Нәфыйков күргәзмәсе ачылды.** Ул үзенең күргәзмәсенә "Мин - катгый рәвештә каршы!" дигән гадәти булмаган исем биргән. Шул рәвештә рәссам халык санын алуга үз мөнәсәбәтен белдерә. Ул татарларны бердәм, бүленмәс милләт дип саный. Рәссам тамашачыларны соңгы ике елда иҗат иткән эшләре белән таныштыра.

Күргәзмәнең исеме кебек үк, анда куелган картиналар да гаять үзенчәлекле. Бу - буяуларның күптөрле палитрасы, геометрик фигуралар, гарәп язуы челтәрләре, төрле таплар, тамчылар... Картиналарның исемнәре дә уйландыра: "Композиция номер ноль", "Сары төстәге тормыш" һ.б. шундыйлар...

Рамин Казан рәсем сәнгате училищесын һәм Латвия рәсем сәнгате академиясен тәмамлаган.

**Рөстәм Абязов җитәкчелегендәге популяр "La Primavera" камера оркестры Туниста узган фестивальдә уңышлы чыгыш ясады.** Якташларыбызның чыгышы тунислылар өчен искитмәле бәйрәмгә әверелде. Концертларга 20 меңләп тамашачы килгән иде. Бигрәк тә оркестр солисты, Россиянең атказанган артисты, Башкортстанның халык артисты Идрис Газиевның искиткеч чыгышы африкалыларны сокландырды.

**Инде өченче ел рәттән Югары Ослан районының Кызыл Байрак авылында алдынгы җәмәгатьчелек вәкилләре, язучылар, артистлар, композиторлар, галимнәр үзенчәлекле бәйрәмгә җыела. Алар бирегә бөек татар композиторы Салих Сәйдәшевны хөрмәтләп искә алырга киләләр.** Бу авылда мәгърур Идел ярында композиторга зурлап истәлек ташы куелган.

Г. Камал исемендәге театр директоры Ш. Закиров җитәкчелегендә оештырылган бәйрәмдә бу юлы күренекле сәхнә осталары белән рәттән яшь башкаручылар да катнашты. Идел яры "сәхнәсе"ендә Камал театры артистлары катнашында "Зәңгәр шәл", "Сүнгән йолдызлар" спектакльләреннән өзекләр күрсәтелде, шигырьләр яңгырады. Дәүләт җыр һәм бию ансамбле дәртләнеп милли биюләр башкарды.

**Казанда күренекле журналист һәм җәмәгать эшлеклесе Шәмси Хамматовка багышланган мемориаль такта куелды. Бронза барельеф Горький урамында Шәмси Хәбибуллович яшәгән йорт фасадында урнаштырылды.**

Мемориаль тактаны ТР Дәүләт Советының фән, мәгариф, мәдәният һәм милли мәсьәләләр буенча даими комиссиясе рәисе Разил Вәлиев һәм "Ватаным Татарстан" газетасы баш мөхәррире Габделхак Шәмсетдинов ачты.

Әлеге чарада төрле рәсми кешеләр, җәмәгать оешмалары, иҗат берләшмәләре вәкилләре, Бөтендөнья татар конгрессы делегатлары һәм кунаклары катнашты.

Чыгыш ясаучылар бу талантлы җитәкчене, яхшы оештыручы һәм рәхимле остазны җылы хисләр белән искә алдылар.

Тантанада катнашучылар Казанның бер урамына Шәмси Хамматов исемен бирү тәкъдимен дә хупладылар.

**"Казан" милли-мәдәни үзәгендә "Казан утлары" журналының 80 еллыгына багышланган әдәбият-сәнгать кичәсе булып узды.**

Бу күркәм бәйрәм язучыларныкы гына түгел, укучыларныкы да. Чыннан да шулай. Өр-яңа һәм иң яхшы әдәби әсәрләрнең журнал битләрендә басылуын түземсезлек белән иң әүвәле алар көтеп ала.

Журналның түгәрәк юбилеен билгеләп үтәр алдыннан, Татарстан Президенты М. Шәймиев баш мөхәррир Р. Фәйзуллин, күренекле язучылар һәм редколлегия әгъзалары белән очрашты. Илбашы билгеләп үткәнчә, журналның сакланып калуы яхшы күренеш, чөнки ул укучыларга һәрвакыт кирәк.